КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 август г.Казань № 745

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль классларын төзү проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 октябрь, 735 нче карары белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль классларын төзү проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль классларын төзү проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 октябрь, 735 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 май, 334 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гомуми белем бирү оешмалары базасында автомобиль классларын төзү проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

бишенче абзацта «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел;» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Россия Федерациясе законнары белән» сүзләрен «федераль законнар белән « сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 4 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел).»;

9 пунктның өченче абзацында «гомуми белем бирү оешмасы базасында автомобиль сыйныфларын булдыру проектын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрне» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе законнары белән» сүзләрен «федераль законнар белән» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия алучы Вәкаләтле органга субсидиядән файдалану турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында килешүдә каралган тәртип, сроклар һәм форма буенча хисап тапшыра.

Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

гомуми белем бирү оешмалары базасында булдырылган автомобиль класслары саны;

гомуми белем бирү оешмалары базасында төзелгән автомобиль классларының санитар-эпидемиологик нормаларга туры килүе.»;

14 пунктта:

бишенче абзацта «гомуми белем бирү оешмасы базасында автомобиль сыйныфларын булдыру проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрне» сүзләренә, «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Килешүгә үзгәрешләр кертү яклар килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

Бирелгән субсидия субсидия субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен сакламау, шулай ук әлеге Тәртипнең 13 пунктында һәм килешүдә каралган субсидиядән файдалану нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта кире кайтарылырга тиеш.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 151 пункт өстәргә:

«$15^1$. Агымдагы финанс елында субсидия алучы, бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә, агымдагы финанс елында субсидия алу мөмкинлеге булмаган очракта, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне кабат тикшермичә, чираттагы финанс елында субсидия алу хокукына ия.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин